ГЛАВА САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.04.2021 с. Сарманово № 75

«Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районында муниципаль
хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе
турында нигезләмә» 2016 елның 01 февралендәге
35 номерлы Сарман муниципаль районы
Башлыгының карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 12 февралендәге УП-132 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләре реестрларын алып бару эшчәнлеген камилләштерү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең реестрларын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә» үзгәрешләр кертергә:

1.4 пунктында «, шулай ук кәгазь чыганакта» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.1. пунктында «һәм кәгазь чыганакта» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә;

«2.2. Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре реестрын төзү һәм алып бару Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (алга таба - Департамент) тарафыннан мәгълүмат системасында дәүләт органнарында тапшырылган дәүләт хезмәткәрләре реестрлары нигезендә гамәлгә ашырыла».

2.4 пунктының икенче абзацында «атасының исеме» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре реестры һәм җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестры, аларга үзгәрешләр, аларда булган мәгълүматны рөхсәтсез файдаланудан, юкка чыгаруны, модификацияләүдән, блоклаудан, күчерүдән, таратудан, шулай ук башка хокуксыз гамәлләрдән яклауны тәэмин итеп, мәгълүмат системасында саклана.»;

3.4 пункт үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми портал» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Башлыгы Ф. М. Хөснуллин